**Расланды**
**«СтройИнвестИпотека»**
**җаваплылыгы чикле җәмгыяте**
**Генераль директоры Боерыгы**
**17.05.2018 №1/08**

# «ОМЕГА» СӘҮДӘ-КҮҢЕЛ АЧУ ҮЗӘГЕНӘ КИЛҮЧЕЛӘР ӨЧЕН

# ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

## ТЕРМИННАР ҺӘМ БИЛГЕЛӘМӘЛӘР

**СКАҮ** – «Омега» сәүдә-күңел ачу үзәге күчемсез һәм күчмә мөлкәт җыелмасыннан гыйбарәт булган гомуми объект, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: Яр Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 2/19 йорт.

**СКАҮ территориясе** – СКАҮнә килүчеләр өчен аның гомуми территориясе. Шул исәпкә, Администрация тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә, Килүчеләргә:

а) керү катгый тыела торган урыннар (технология бүлмәләре, инженер җиһазлар куелган урыннар, җитештерү эшләре урыннары, ял зонасы һ.б.) (Тыелган зоналар);

б) керү өлешчә чикләнә торган, ягъни билгеле бер шартларда гына керү ихтималы булган урыннар (офис, администрация, склад бүлмәләре, эвакуация яки янгын очраклары өчен запас чыгу юллары һ.б.) (Чикләнгән зоналар);

в) СКАҮнең эш режимына ярашлы рәвештә керү рөхсәт ителә торган урыннар, әгәр Администрация тарафыннан махсус чикләнмәгән булса (атриум, вестибюль, бәдрәф, гомуми аралык һ. б.) (Ирекле зоналар).

Сәүдә-күңел ачу үзәгендә ирекле зоналар бары тик ял итү, ашау (җәмәгать туклану пунктларында), сатып алу һәм күңел ачу өчен генә билгеләнгән.

**Администрация** – җаваплылыгы чикле «СтройИнвестИпотека» җәмгыяте, СКАҮ белән идарә итүче я (яки) СКАҮнең хуҗасы вәкаләт биргән затлар.

**Килүчеләр** – бары тик шәхси, гаилә һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен товар (эш, хезмәт) сатып алу яки аңа заказ бирү максаты белән СКАҮнә килүче затлар.

**Куркынычсызлык хезмәте** – (ШСО хезмәткәре, СКАҮ администраторы) иминлек һәм тәртип саклау, Килүчеләрнең СКАҮнә керүен оештыру һәм кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тоту вазыйфаларын башкаручы зат.

**Җәмәгать туклануы пункты** – «Омега» СКАҮ территориясендә урнашкан рестораннар, кафе, фудкорт операторлары.

## 1 бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. «Омега» СКАҮнә Килүчеләрнең гамәлдәге үз-үзеңне тоту кагыйдәләре (текстта алга таба – «Кагыйдәләр») – Администрация тарафыннан билгеләнгән, Килүчеләр (аерым төркемнәр) мәҗбүри үтәргә тиешле норма һәм таләпләре булган локаль норматив акт. Бу кагыйдәләр сәүдә-күңел ачу үзәгенә Килүчеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, бинаны имин эксплуатацияләү, террорчылыкка каршы һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук Килүчеләрнең хокук һәм мәнфәгатьләрен яклау максатын күздә тота.

Кагыйдәләр Килүчеләр игътибарына СКАҮнең мәгълүмати стендларына, үзәкнең рәсми сайтына, (http://tc-omega.info) интернет адресына урнаштыру юлы белән җиткерелә.

Кагыйдәләрдәге үзгәрешләр Килүчеләргә СКАҮ Администрациясе тарафыннан шул ук тәртиптә җиткерелә.

1.2. Сәүдә-күңел ачу үзәгенә Килүчеләр, шул исәптән СКАҮ территориясенә караган паркинг, җәмәгать туклану зонасында (фудкорт) булучылар үтәргә бурычлы:

- РФ законнары тарафыннан билгеләнгән җәмәгать урыннарында гомумкабул ителгән үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен;
- янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен;
- Администрация, Куркынычсызлык хезмәте хезмәткәрләре һәм полиция таләпләрен;
- парковка хезмәтләреннән файдалану кагыйдәләрен;
- гамәлдәге фудкорт кагыйдәләрен;
- СКАҮндә хәзерге вакыта гамәлдә булган Кагыйдәләрне.

1.3. СКАҮ территориясе хосусый милек булып тора, шуңа бәйле рәвештә, СКАҮнең хуҗасы, килешү ирeклеге, намуслылык, диспозитивлык, хосусый милек иминлеге принципларын үтәп, гамәлдәге Кагыйдәләрнең эчтәлеген һәм СКАҮнә килүчеләрнең шул территориядә булу шартларын мөстәкыйль рәвештә билгели (Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 1, 10, 14, 209 нчы маддәләре). СКАҮ территориясендә тиешле тәртипне тәэмин итү максатында, Администрация, шулай ук Куркынычсызлык хезмәте хезмәткәрләре фото- һәм видеоконтроль башкарырга хокуклы.

1.4. СКАҮнә һәм аңа караган территориягә килүчеләр Кагыйдәләр белән тулысынча килешәләр, кабул итәләр һәм аларны тайпылышсыз үтәргә бурычлылар.

Кагыйдәләр белән тулысынча яисә нинди дә булса өлешендәге таләпләр белән, Администрация, Куркынычсызлык хезмәте таләпләре белән килешмәгән очракта, СКАҮнә Килүче монда килүдән баш тартырга яки әлеге территориядән чыгып китәргә тиеш.

СКАҮнә керү тыелган зат СКАҮ территориясеннән кичекмәстән чыгып китәргә тиеш һәм аңа үтеп керергә омтылырга тиеш түгел.

СКАҮнә килүчеләр, Куркынычсызлык хезмәте хезмәткәрләренең гамәлләре кагыйдәләргә туры килми дип уйлаган очракта, СКАҮ Администраторына мөрәҗәгать итеп, шикаять бирергә мөмкин. Күрсәтелгән гамәлләргә шикаять бирелсә дә, Куркынычсызлык хезмәте таләпләрен үтәү зарурлыгы саклана.

1.5. «Омега» СКАҮндә эш сәгате түбәндәгечә билгеләнгән:

«Омега» СКАҮ: 09:00 – 21:00. Көн саен (01 гыйнвардан кала);

Парковка: СКАҮнең эш режимына карап. Көн саен.

Аерым сәүдә павильоннары һәм сервис хезмәтләренең эш графигы СКАҮ графигыннан аерылырга мөмкин, Килүчеләргә мәгълүматлар СКАҮнең мәгълүмат сайтына урнаштыру юлы белән җиткерелә.

1.6. Администрация Килүчеләргә товар сату, эш, хезмәт күрсәтү кебек гамәлләр башкармаганлыктан, Гражданнар Кодексының ачыктан-ачык килешү турындагы кагыйдәләрне үз эченә алган 426 нчы маддәсе һәм кулланучылар хокукларын яклау турындагы закон аңа кагылмый.

Администрация СКАҮндә килешү буенча эшләүче арендаторларның товарларын (эшен, хезмәтен) алу максаты белән СКАҮнә Килүчеләргә гамәлләрен тормышка ашырырга мөмкинлек тудыра. Килүче үтенече буенча, Администрация аның арендаторларга мөнәсәбәтле мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклауда ярдәм күрсәтергә хокуклы.

1.7. Администрация СКАҮнең аерым кешеләр биләмәсе һәм/яки өченче затлар кулланылышында булмаган территориясенә керергә рөхсәт ителгән Килүчеләргә уңайлы шартлар тудыра һәм куркынычсызлык чараларын күрә, Килүчеләрнең үзенә яки аларның мөлкәтенә зыян китерүгә юл куймый.

1.8. СКАҮнә тулаем яки аның аерым бер өлешләренә керүне Администрация түбәндәге юллар белән чикләргә мөмкин:

- СКАҮнә килүчеләр керергә тыела яки чикләнә торган урыннарны билгеләп,
- СКАҮнең яки аның аерым өлешләренең эш режимын билгеләп,
- СКАҮнең аерым өлешләренә һәм/яки аерым бер вакытта үткәрү режимын кертеп,
- Кагыйдәләрне үтәмәүче Килүчеләрне СКАҮнә кертүдән баш тартып.

## 2 бүлек. КИЛҮЧЕЛӘРНЕҢ ҮЗ-ҮЗЕН ТОТЫШЫНА ТАЛӘПЛӘР

2.1 . **Килүчеләргә тыела:**

2.1.1. Аерым билгеләнмәгән урыннарда тәмәке тарту. Табиб билгеләве булмаган очракта, наркотик, психотроп, аңны томаландыручы матдәләрне куллану һәм тарату. СКАҮ территориясендә, җиңелчә хәмерле продукция сатыла торган җәмәгать туклануы пунктларыннан тыш, сыра һәм аның нигезендә ясалган эчемлекләр, алкогольле һәм спиртлы продукция эчү.

2.1.2. СКАҮ территориясенә хәмер, наркотик, токсикологик, психотроп матдәләр тәэсире нәтиҗәсендә иҗтимагый әхлакны бозучы һәм кешелек дәрәҗәсен кимсетүче исерек халәттә булу.

СКАҮдә киемсез, ялангач торс белән, яки башкаларны ихтирам итмәүне күрсәтеп торучы, яки иҗтимагый әхлакны бозарлык һәм кешелек дәрәҗәсен кимсетерлек тышкы кыяфәттә булу.

2.1.3. СКАҮ территориясенә:

- шартлаткыч матдәләр, шартлаткыч җайланмалар;
- теләсә нинди корал һәм (яки) аның патроннары, сугыш кирәк-яраклары;
- үз-үзеңне саклау чаралары: электрошок җайланмалары, барлык төрдәге механик һәм автомат аэрозоль сиптергечләр;
- агулы матдәләр;
- кадаучы, кисүче предметлар;
- пиротехник чаралар алып керү.

СКАҮ территориясенә үзенең хезмәт вазыйфаларын башкарганда корал йөртергә хокукы булган хокук саклау органнары хезмәткәрләренә генә корал белән керергә ярый.

2.1.4. Җәмәгать тәртибен бозу, тупас, сүгенү сүзләре әйтеп, мыскыллап бәйләнеп, гражданнарга карата ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтү. Бәхәс, ызгыш-талаш, сугыш һәм башка конфликтларның инициаторы булу, аларда катнашу, әйләнә-тирәдәгеләргә агрессия күрсәтү, хулиганлык гамәлләре кылу.

Гражданнарга карата ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтерлек, иҗтимагый әхлакны бозарлык һәм кешелек дәрәҗәсен кимсетерлек, өченче кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә яки мөлкәтенә зыян китерерлек, яки андый зыян китерү куркынычы тудырырлык башка гамәлләр кылу.

2.1.5. Законсыз яисә Администрация белән килешенмәгән җыелышлар уздыру, аларда катнашу, шул исәптән төрле төрдәге лозунглар, плакатлар, транспарантлар куллану.

Администрация белән килешмичә, нинди дә булса маркетинг, конкурс, реклама, пропаганда, агитация чаралары (музыкаль һәм театраль чыгышларны кертеп) үткәрү, реклама һәм башка мәгълүматны тарату, акча, тавыш, ставкалар җыю, теләсә кайсы сәүдә яки башка коммерция эшчәнлеген башкару.

Комарлы уеннар оештыру һәм аларда катнашу. Сукбайлык һәм теләнчелек белән шөгыльләнү.

2.1.6. СКАҮгә килүчеләргә комачаулаучы, тынлыкны бозучы урынлы булмаган шау-шу тудыру, музыкаль уен коралларында уйнау, тавышкөчәйткеч куллану, радио, компакт дисклар һәм башка аудиоязмалар уйнату.

2.1.7. СКАҮ Администрациясе рөхсәтеннән башка фото һәм/яки видеога төшерү, фотосессия үткәрү.

2.1.8. Администрация белән килешмичә, Тыелган яки Чикләнгән зоналарга үтеп керергә омтылу.

2.1.9. Балаларны караучысыз калдыру.

2.1.10. СКАҮ территориясенә хайваннар, рептилияләр, кошлар белән керү (искәрмә: җитәкләп йөрүче этләр рөхсәт ителә).

2.1.11. Сумка һәм шәхси әйберләрне караучысыз калдыру.

2.1.12. Йөгерү, сикерү, киртәгә, култыксага, техник корылмаларга менү, тиешле мәгълүмат таблолары белән тәэмин ителгән яшелләндерелгән территориягә, хезмәт биналарына керү, теләсә нинди биеклектән сикерү. Баскычларда, идәннәрдә, киртәләрдә һәм тротуарларда утыру.

2.1.13. Сәүдә бүлмәләре һәм гомуми файдаланудагы урыннар буйлап роликлы тимераякта, скейтбордта, сигвейда, гироскутерда , самакатлар һәм велосипедта йөрү (искәрмә: СКАҮ арендаторлары  прокатка тәкъдим иткән чаралар).

Велосипедларны СКАҮнең уртак зонасында махсус урнаштырылган парковка рампаларыннан читтә саклау.

2.1.14. Тиешле мәгълүмат эленгән очракта, бәдрәф бүлмәләрен җыештырган вакытта анда керү. СКАҮнең фойесенда һәм санузелда шома плитка җәелгән юеш идәндә йөрү.

2.1.15. СКАҮнең яки кешеләрнең мөлкәтен бозу, аңа законсыз кул сузу. СКАҮнең җиһазларына, бизәү әйберләренә, елка уенчыкларына, декор элементларына, киртәләргә, реклама такталары һәм башка инвентарьларга, шулай ук уен һәм күңел ачу өчен билгеләнмәгән электр корылмаларына кагылу һәм урыныннан күчерү.

2.1.16. 21:00 сәгатьтән соң Килүчеләргә СКАҮ территориясендә булырга рөхсәт ителми.

2.2. **Килүчеләрнең бурычы:**

2.2.1. СКАҮ кагыйдәләре нигезендә аның территориясенә алып керергә рөхсәт ителми торган предметлар булу турында Куркынычсызлык хезмәтенә хәбәр итәргә, андый әйберләрне калдырып керергә (шәхси транспортта яки махсус саклау камералары булган очракта, шунда калдырырга).

2.2.2. Зур габаритлы сумкаларны, тартмаларны, тикшерү өчен, Куркынычсызлык хезмәте хезмәткәрләренә күрсәтергә. Әлеге таләпне үтәү СКАҮнә Килүчене кертүнең бер шарты яки аның билгеле бер өлеше булып тора.

2.2.3. Закон, Администрация, Куркынычсызлык хезмәте таләп иткән кагыйдәләрне үтәргә.

2.2.4. Администрация, Куркынычсызлык хезмәте таләп иткән очракта СКАҮ территориясеннннән чыгып китәргә.

2.2.5. Гамәлдәге законнарны, кагыйдәләрне, янгын куркынычсызлыгы, юл хәрәкәте, шулай ук сәүдә арендаторлары һәм СКАҮ территориясендә эшчәнлек алып баручы башка эшмәкәрләр урнаштырган кагыйдәләрне үтәргә.

2.3. **Килүчеләр хокуклы:**

2.3.1. СКАҮ, Администрация, арендаторларның эш режимы, СКАҮндә гамәлдә булган кагыйдәләр турында тулы мәгълүмат алырга.

2.3.2. СКАҮнең эш режимына ярашлы рәвештә һәм кагыйдәләрне үтәгән хәлдә аның Ирекле зоналарында һәм аның аерым өлешләрендә булырга.

2.3.3. СКАҮ хезмәткәрләре һәм арендаторларының компетентлы һәм ихтирам белән күрсәтелгән хезмәтләреннән файдаланырга, шикаять язу кенәгәсен таләп итәргә.

Бүлек 3. КИЛҮЧЕЛӘРНЕҢ ФУДКОРТТА БУЛУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Гамәлдәге Кагыйдәләр СКАҮнә Килүчеләрнең, Администрациянең һәм Куркынычсызлык хезмәтенең хокукларын һәм бурычларын билгели, һәм ул фудкортның эш вакытында барлык катнашучыларга уңайлы халәт тудыруга юнәлтелгән. Кагыйдәләр үзәккә Килүчеләрнең барысы өчен дә мәҗбүри санала. Килүче, фудкорт зонасында урнашырга карар кылып, әлеге кагыйдәләрне үтәячәген раслый. Фудкорт шәхси милек булып саналганлыктан, СКАҮ Администрациясе, сәбәбен аңлатмыйча, аның территориясенә керүне чикләү хокукына ия. Тиешле тәртипне тәэмин итү максатында СКАҮ Администрациясе фото- һәм видеокүзәтүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

**КИЛҮЧЕЛӘРНЕҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ**

**Фудкортка Килүчеләр үтәргә бурычлы:**

• җәмәгать тәртибен сакларга;

• үзе теләп алган ризык һәм эчемлекләр өчен түләргә;

• башка килүчеләргә комачауламаска;

• чисталык сакларга;

• сәүдә үзәге милкенә (җиһаз, савыт-саба, сантехника һәм башкаларга) сак карарга, ә милеккә зыян килгән очракта, әлеге зыянны түләргә;

• Куркынычсызлык хезмәте хезмәткәрләре таләбе буенча шәхесне раслаучы документларны күрсәтергә;

• гамәлдәге Кагыйдәләрне үтәргә.

**Фудкортка Килүчеләр хокуклы:**

• түләүне акча яки банк картасы аша башкарырга;

• барлык кагыйдәләрне үтәгән хәлдә кафега балалар белән керергә.

**Килүчеләргә тыела:**

• тәмәке, электрон тәмәке, кальян, тәмәке булмаган әйберләр тарту;

• СКАҮнә хайваннар һәм кошлар, велосипед һәм башка транспорт чаралары (балалар һәм инвалидлар өчен махсус коляскалардан башка), тиз янып китүчән, шартлаткыч, агулый торган, агулы, наркотик һәм психотроп матдәләр, ату кораллары, кадый һәм кисә торган әйберләр алып керү;

• наркотик кулланган, агу иснәгән яки бик нык исерек халәттә булу, каты исерткеч эчемлекләр, наркотик чаралар яки психотроп матдәләр куллану;

• интерьер җиһазларын яки башка килүчеләрне пычратырдай пөхтә булмаган, ертык яки пычрак өс киеме һәм аяк киеме белән йөрү;

• Килүчеләргә, Администрация, Куркынычсызлык хезмәте һәм фудкорт хезмәткәрләренә тупаслык күрсәтү;

• ызгы-талаш оештыру һәм сугышу.

• сызгыру һәм кычкырып, тавыш күтәреп сөйләшү;

• тавыш көчәйткечләр куллану (колак аппаратыннан кала) һәм колакчыннарсыз (наушник) аудиоязма яки аудио трансляцияләр тыңлау;

• Администрация белән килешмичә, фото һәм видеога төшерү;

• Килүчеләрнең, Администрациясе хезмәткәрләренең юлын каплау яки башка ысул белән аларга хәрәкәтләнергә комачаулык итү;

• Килүчеләрнең чакыруыннан башка аларның өстәленә килеп утыру;
• Администрация рөхсәтеннән башка буш өстәлләрне урыныннан күчерү;
• карта яки башка комарлы уеннар, шулай ук команда белән сюжетлы уеннар уйнау;
• үзең белән алып килгән ризык һәм эчемлекләрне ашау-эчү өчен фудкорт зонасын куллану;
• фудкорт операторлары хезмәтләреннән файдалану белән бәйле булмаган очракта ирекле өстәлләрне куллану;
• идәндә утыру, җиһазга аяк белән басу;
• өстәл өстендә, култыксаларда утыру яки бию;
• җәмәгать тәртибен һәм башка Килүчеләрнең тынычлыгын бозу;
• СКАҮ һәм фудкорт операторлары мөлкәтенә зыян салу;
• Администрация рөхсәтеннән башка хезмәт урыны бүлмәләренә керү.

## ГАМӘЛДӘГЕ КАГЫЙДӘЛӘРНЕ БОЗГАН ӨЧЕН ҖАВАПЛЫЛЫК

Гамәлдәге Кагыйдәләрне бозган очракта, Администрациянең хокукы бар:
- кагыйдәләрне бозуны фото- һәм видеога теркәргә;
- полиция, Куркынычсызлык хезмәтен чакыртырга һәм тикшерү уздыруны һәм хокук бозучыны законда билгеләнгән җаваплылыкка тартуны сорап хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә;
- кагыйдәләрне бозучыны фудкорт территориясеннән чыгарырга һәм аны хокук саклау органнары хезмәткәрләренә тапшырырга;
- кагыйдә бозучыны алга таба СКАҮнә кертмәскә;
- СКАҮ мөлкәтенә зыян салган очракта гаепледән аның тулы бәясен түләтергә;

Югарыда күрсәтелгән чараларны куллануның сәбәбе булып шулай ук Куркынычсызлык хезмәте хезмәткәре тарафыннан Килүчеләрнең теләсә нинди формада агрессия күрсәтүе һәм тәртипсезлек кылуы, наркотик кулланган, агу иснәгән, яки исерек халәттә булуын күрсәтүче билгеләрнең ачыклануы һәм ресторандагы башка кунакларга уңайсызлык тудыруы тора.

## Бүлек 4. ЭСКАЛАТОРДАН ФАЙДАЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

4.1 Эскалаторда вакытта:

4.1.1. Хәрәкәтләнүче лентада хәрәкәт юнәлешенә йөз белән карап, култыксага кул белән тотынып басып торырга.

4.1.2. Абынмас һәм алда торган кешегә басмас өчен, кимендә бер баскыч аркылы басарга.

4.1.3. Сул яктагы култыксага кул белән тотынып, сул яктан әйленеп үтәргә.

4.1.4. Эскалатордан идәнгә төшкәндә игътибарлы булырга.

4.1.5. Хәрәкәтләнүче эскалатор баскычыннан сумка, тележка һәм башка шундый әйберләрне күтәреп алып куярга.

4.1.6. Балаларны күтәрергә яки җитәкләргә.

4.1.7. Пассажир эскалаторда егылган вакытта «Стоп» сүндергечен кулланырга.

4.1.8. Әйберләр эскалаторның тарагына төшеп киткән очракта, «Стоп» сүндергече ярдәмендә туктатырга һәм дежурныйга мөрәҗәгать итәргә.

4.1.9. Эскалатор кисәк туктаган очракта, дежурныйның бөтен таләпләрен үтәргә.

4.2. Эскалаторда вакытта тыела:
• хәрәкәтләнүче лента буйлап йөгерү;

- хәрәкәтләнүче экалаторның каршысына бару;
- баскычта утыру; конструкциянең хәрәкәтләнми торган өлешләренә сөялү;
- култыксага таяну;
- эскалаторның тупсасында күрсәтелгән саргылт төстәге чик линиясеннән чыгу;
- эскалаторның култыксасына утыру яки әйберләр кую;
- балаларны караучысыз калдыру;
- китаплар, гәзитләр уку;
- аяк киемсез булу.
- 

4.3. Тәкъдим ителә:

4.3.1. Озын киемнең итәген тотарга.

4.3.2. Үкчәле аяк киеме белән эскалаторда игътибарлы булырга.

4.3.3. Кул йөген (багаж, сумка...) контрольдә тотарга;

4.3.4. Хәрәкәтләнүче лентадан төшкәндә, алдан әзерләнеп куярга;

4.3.5. Эскалатордан төшкәндә тоткарланмаска.

4.4. Рөхсәт ителми:

- киртә куелган, эшләми торган эскалаторга керергә;
- кирәк-кирәкмәскә «Стоп» сүндергечен кулланырга.

4.5. Эскалаторда бәхетсезлек очрагының шаһиты булсагыз, эскалаторны туктатырга, кичекмәстән бу турыда үзәкнең Администраторына хәбәр итәргә кирәк.

## Бүлек 5. ЛИФТТАН ФАЙДАЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

5.1. Лифттан беренче чиратта файдаланырга хокуклы затлар: инвалидлар, авырлы хатыннар, бала белән, бала коляскасы белән килүчеләр, өлкән яшьтәгеләр.

5.2. Этажга кабинаны чакыру өчен, лифт янындагы кнопкага басарга кирәк. Кабина этажга килгәч, ишекләр автомат рәвештә ачыла. Идарә итү панелендә лифтның ничә кешегә исәпләнгән булы, ягъни пассажирлар саны күрсәтелгән. Кабинада пассажирлар саны тиешле саннан күбрәк булган очракта, кабина кузгалмаячак, пассажирларның берәрсенә чыгарга туры киләчәк. Лифтның ишекләре автомат рәвештә ябыла.

5.3. Ишекләр ябылган вакытта, ишектән керә торган юлда кеше яки багаж торса, идарә итү панелендәге «ОТКРЫТИЕ ДВЕРЕЙ» дигән кнопкага басарга кирәк. Лифтта артык пассажир булганда да, аны лифттан чыгару өчен, шул кнопкадан файдаланырга була.

5.4. Лифт төзек булмаган очракта, техник персонал тревога кнопкасына (кнопкада кыңгырау сурәтләнгән) басып чакырыла. Лифтта сөйләшү элемтәсе булса, сөйләшү җайланмасы рәшәткәсенә (идарә итү панеленең урта өлешендә урнашкан) каршы басып диспетчер белән сөйләшегез, авария хезмәте килеп җиткәнче, төзек булмаган лифттан мөстәкыйль рәвештә чыгарга омтылмагыз.

ИСТӘ ТОТЫГЫЗ: төзек булмаган лифттан мөстәкыйль рәвештә чыгарга омтылу ТОРМЫШ ӨЧЕН КУРКЫНЫЧ!

5.5. Арендаторлар һәм СКАҮнә килүчеләр бурычлы:

5.5.1 Лифтта урнаштырылган лифттан файдалану кагыйдәләрен берсүзсез үтәргә, лифт җиһазларына сак карарга, лифт кабинасында тәртип һәм чисталыкны сакларга;

5.5.2. Лифттагы кешеләр саны рөхсәт ителгәннән артык булмаска тиеш. Тавышлы сигнал барлыкка килгәндә, пассажирларның бер өлеше кабинадан чыгарга тиеш.

5.4. Лифт кабинасында тыела:

5.4.1. Лифтның тышкы өлешенә зыян китерерлек җиһаз һәм йөкләрне лифтка кертү;

5.4.2. Шартлау һәм янгын куркынычы тудырырдай һәм агулы матдәләрне лифтка кертү;

5.4.2. Туктап калган лифт кабинасыннан мөстәкыйль рәвештә чыгарга омтылу;

5.4.3. Лифт кабинасында теләсә нинди төрдәге мәгълүмати, агитацион һәм реклама материалларын урнаштыру;

5.4.4. Фотосессияләр үткәрү һәм этажда лифтны тоткарлау;

5.4.5. Лифтта аның кабинасының мәгълүмати таблосында күрсәтелгәннән артык кешеләр булу. Тавышлы сигнал барлыкка килгәндә, пассажирларның бер өлеше кабинадан чыгарга тиеш.

5.4.6. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның зурлардан башка лифтка керүе.

## <u>6 бүлек. ҖИР ӨСТЕ ПАРКОВКАСЫННАН ФАЙДАЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ</u>

6.1. Администрация СКАҮгә килүчеләргә, парковканың эш режимын һәм кагыйдәләрен үтәгән хәлдә, транспорт чаралары белән түләүсез Парковкага керергә рөхсәт итә, ләкин Килүчеләргә сак хезмәте күрсәтми һәм (яки) транспорт чараларын сакламый, шул сәбәпле транспорт чараларының сакланышы өчен, шулай ук өченче бер кешеләрнең транспорт чараларына зыян китерүләре өчен ул җаваплы түгел

6.2. Парковка территориясендә хәрәкәт итү, туктап тору, тукталыш, шул исәптән юл билгеләре, тамгаларга игътибар итеп хәрәкәт итү Россия Федерациянең Юл хәрәкәте кагыйдәләренә (ЮХК) ярашлы рәвештә тормышка ашырыла (п.1.2 ЮХК),  шулай ук Администрация һәм Куркынычсызлык хезмәтенең гамәлдәге Кагыйдәләрен һәм күрсәтмәләрен үтәү таләп ителә.

6.3. Администрация, федераль законнарга ярашлы рәвештә («Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы турында»гы Федераль законның 21 нче маддәсе, 1 п. белән (10.12.1995 N 196-ФЗ), «Россия Федерациясенең автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль законның 3 нче маддәсе, 6, 12 п., 4 б. 15 маддә, 1 б. 17 маддә, 3 б. 27 нче маддә белән (08.11.2007 N 257-ФЗ)) парковкадан файдалану кагыйдәләрен мөстәкыйль билгели һәм аның, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында, СКАҮгә килүчеләрнең Кагыйдәләрне бозып куелган һәм (яки) җәяүлеләрнең хәрәкәтенә комачаулый торган транспорт чараларын күчерергә (Парковка территориясеннән чыгарырга) хокукы бар. Күрсәтелгән очракларда, транспорт чараларына һәм башка төрдәге милеккә очраклы рәвештә зыян килсә, кагыйдәләрне бозган СКАҮгә Килүче җавап бирә.

6.4. СКАҮгә Килүчеләр тизлек режимын үтәргә бурычлы (Парковка территориясендә хәрәкәт итү тизлеге:  сәгатенә 10  километрдан артык түгел).

6.5. СКАҮгә Килүчеләргә тыела:

6.5.1.  Транспорт чаралары хәрәкәтен рөхсәт ителгән тизлектән законсыз шактый арттыру (30 км/сәгатьтән арттыру), аңлы рәвештә тизлекне кискен арттыру, тормозга басу, хәрәкәт юнәлешен үзгәртү, көчле тавыш, шау-шу тудыру (агрессив йөртү).

6.5.2. Юл хәрәкәте кагыйдәләре, юл билгеләре, тамгалары таләпләрен бозу.

6.5.3. Газонга, үтеп йөрү, керү, чыгу өлешләренә, парковка «кесәсе» зонасына керми торган урынга, СКАҮ территориясендә урнашкан өстәмә биналарның ишеге янына, инвалидлар куя торган урынга (аңа хокукы булмаган очракта), шулай ук тамга белән билгеләнгән махсус парковка урыннарыннан тыш башка теләсә нинди урынга автотранспортны кую.

6.5.4. Транспорт чарасын юл билгеләрен яки тамгаларын бозып туктату яки стоянкага кую, шул исәптән авария булган очракта (авария тукталышы билгесен кабызып) туктап тору, СКАҮнә керә торган җирдә пассажирларны төшерү  яки утырту, башкача

әйткәндә транспорт хәрәкәтенә теләсә нинди тоткарлык ясау, транспорт хәрәкәте өчен билгеләнгән территориянең үткәрү сәләтен киметү.

6.5.5. СКАҮ Администрациясе белән килешү булмаган очракта, зур йөк машиналары, тракторлар, зур автобуслар белән парковкага керү.

6.5.6. Рөхсәт ителәгән максималь массасы 2,5 тонна булган һәм/яки бер парковка урыныннан күбрәк урын биләүче йөк автомобильләрен парковкага кую.

6.5.7. Супермаркетның тележкаларын кулланган очракта, товарны парковка «кесәсеннән» тыш зонада бушату, тележканы үтеп йөри торган урында калдыру яки аның белән парковка урыннарын каплау, аларны СКАҮ территорисеннән алып чыгу, контрольсез күчерү, алар белән транспорт чараларына зыян китерү.

6.5.8. Автотранспортны СКАҮ территориясендә төнгә калдыру.

6.5.9. Автомобильне ремонтлау, аңа техник хезмәт күрсәтү, шулай ук юу.

6.5.10. Парковкадагы юл катламын, юл билгеләрен, тамгаларны һәм башка мөлкәтне җимерү, бозу.

6.5.11. СКАҮ Администрациясенең язма рөхсәтеннән башка коммерция, реклама, агитация чаралары үткәрү.

6.5.12. Иганәчелек эше белән шөгыльләнү, листовкалар тарату.

6.5.13. Җәяүлеләр хәрәкәте һәм транспорт чараларының хәрәкәт итүе яки туктап торуы белән бәйле булмаган максатларда, шул исәптән теләсә нинди төрдәге ярышлар, узышлар, җыелышлар уздыру максатыннан куллану.

6.5.14. Исерткеч эчемлекләр һәм сыра эчү.

6.5.15. Бәхетсезлек очракларын булдырмау максатында, машиналар йөри һәм туктап тора торган урыннарда роликлы тимераякта, скейтбордта, велосипедта һәм башкаларда йөрү.

6.6. СКАҮ Килүчеләрнең парковка территориясендә калдырылган әйберләре өчен җавап бирми.

6.7. Парковкада яки аңа керә торган урында юл-транспорт һәлакәте булган очракта, Килүче ЮХК таләпләрен үтәргә, юл-транспорт һәлакәте нәтиҗәләрен тизрәк бетерү һәм транспорт чараларының тоткарлыксыз хәрәкәтен торгызу максатында, кичекмәстән Администрация һәм Куркынычсызлык хезмәтенә хәбәр итәргә бурычлы.

6.8. Администрациянең, нинди дә булса чара үткәргән очракта яки кирәк булганда, парковкага һәм аның аерым өлешләренә керү юлын ябарга, шулай ук аерым затларга (мәсәлән, СКАҮнең хезмәткәрләренә, арендаторларга) транспорт чараларының кайбер категорияләренә парковка ясау урыннарын билгеләү хокукы бар.

6.9. Тиеш булмаган урында куеп калдырылган транспорт чаралары эвакуацияләнергә мөмкин. Куркынычсызлык хезмәте хезмәткәрләренең гамәлдәге Кагыйдәләрне бозучыларны туктатырга, кисәтү ясарга яки СКАҮ территориясеннән чыгарып җибәрергә хоукы бар.